**«УТВЕРЖДАЮ»**

Заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр образования и науки Республики Татарстан

_________________ Э.Н. Фаттахов

«____» _________________ 2015 год

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов единого республиканского тестирования ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ для обучающихся IX классов, изучающих татарский язык в русскоязычных группах общеобразовательных организаций с русским языком обучения

Подготовлено Министерством образования и науки Республики Татарстан

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының рус төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты**

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән тест эше 38 биремне үз эченә алган 4 бүлектән тора. 1 нче бүлек 8 биремнән тора (1нче – 8 нче биремнәр). Алар укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. Тәкъдим ителә торган башкару вакыты – 30 минут. 2 нче бүлек 9 биремнән тора (9 нчы – 17 нче биремнәр). Алар укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. Тәкъдим ителә торган башкару вакыты – 30 минут. 3 нче бүлек 15 биремнән тора (18 нче – 32 нче биремнәр). Алар укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. Башкару вакыты – 30 минут. 4 нче бүлек 2 өлештән тора. 33 нче – 37 нче биремнәр сөйләм ситуацияләренә караган репликалар язуны күздә тота. Тәкъдим ителгән башкару вакыты - 20 минут. Ачык типтагы 38 нче бирем укучыларның язма сөйләмен тикшерүдән гыйбарәт. Башкару вакыты - 40 минут.

**Уңышлар телибез!**

*****

**Единое республиканское тестирование по ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ для обучающихся, изучающих татарский язык в русских группах общеобразовательных организаций с русским языком обучения**

## Инструкция по выполнению работы

Тестовая работа по татарскому языку состоит из четырех разделов, включающих 38 заданий. Раздел 1 (задания по аудированию) включает 8 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1-8). Рекомендуемое время на выполнение данного раздела – 30 минут. Раздел 2 (задания по чтению) включает в себя 9 заданий (задания 9-17). Рекомендуемое время на выполнение данного раздела – 30 минут. Раздел 3 (задания по лексике и грамматике) состоит из 15 заданий (задания 18-32). Рекомендуемое время на выполнение – 30 минут. Раздел 4 (задания по письму) состоит из двух частей. В заданиях 33-37 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией. Рекомендуемое время на выполнение – 20 минут. В задании 38 предлагается написать личное письмо. Рекомендуемое время на выполнение – 40 минут.

**Желаем успеха!**

## 1 нче бүлек

Ответом к заданиям 1-8 является последовательность цифр, запишите её в бланке ответов № 1 справа от номера соответствующего задания, начиная с первой клеточки. При переносе ответа на бланк следует указать только эту последовательность, **без запятых, пробелов и прочих символов.** Каждый символ пишите в отдельной клеточке в соответствии с приведёнными образцами.

**1** Вы услышите четыре коротких диалога, обозначенных **А, Ә, Б и В**. Определите, где происходит каждый из этих диалогов. Используйте каждое место действия из списка **1-5 только один раз.** В задании есть **одно лишнее место действия.**
Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу.

1. Китап кибетендә
2. Бакчада
3. Театрда
4. Вокзалда
5. Сәүдә үзәгендә

Ответ:

| **Диалог** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** |
|---|---|---|---|---|
| **Место действия** | | | | |

**2** Вы услышите пять высказываний. Установите соответствие между высказываниями каждого говорящего **А – Г** и утверждениями, данными в списке **1 - 6.** Используйте каждое утверждение из списка 1-6 **только один раз.** В задании есть **одно лишнее утверждение.**
Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу.

1. Сөйләүче Татарстанның башкаласы турында әйтә.
2. Сөйләүче “КамАЗ” заводы турында әйтә.
3. Сөйләүче республиканың мәдәнияте турында әйтә.
4. Сөйләүче Татарстанның сәнәгате турында әйтә.
5. Сөйләүче башкалабызның спорт корылмалары турында әйтә.
6. Сөйләүче туган авылы турында әйтә.

Ответ:

| **Говорящий** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** |
|---|---|---|---|---|---|
| **Утверждение** | | | | | |

Вы услышите разговор двух друзей. В заданиях 3 – 8 обведите цифру 1, 2 или 3, соответствующую выбранному Вами варианту ответа.

Вы услышите запись дважды.

**3** Мөнирә … белән шөгыльләнә.

1) гимнастика
2) теннис
3) фигуралы шуу

**4** Мөнирә … яшьтән бирле спорт белән шөгыльләнә.

1) ун
2) биш
3) җиде

**5** Мөнирә … беренчелегендә катнашкан.

1) республика
2) Россия
3) шәһәр

**6** Самат … белән кызыксына.

1) музыка
2) спорт
3) компьютер

**7** Самат … катнашкан.

1) ярышта
2) олимпиадада
3) конкурста

**8** Самат … барган.

1) Мәскәүгә
2) Төмәнгә
3) Самарага

**По окончании выполнения заданий 1 - 8 не забудьте перенести свои ответы в бланк ответов № 1. Для заданий 1- 8 поставьте знак «x» в клеточку, номер которой соответствует номеру выбранного Вами ответа.**

## 2 нче бүлек

Прочитайте текст. Определите, какие их приведённых утверждений **9-16** соответствуют содержанию текста (**1 – текстка туры килә**), какие не соответствуют ( **2 – текстка туры килми**).
В бланке ответов № 1 поставьте знак «х» в клеточку, номер которой соответствует номеру выбранного Вами ответа.

Малай яр буенда балык тотып утырганда, бераз читтә, куак арасында әллә нинди тавышлар ишетә башлады. Курыккан, сызгырган һәм башка тавышлар...

Малай кармакларын тиз генә судан чыгарды да тавыш килгән якка китте. Анда, камыш арасында, кошлар сугыша икән. Кечкенә генә камыш чыпчыклары олы бер кошны кыйныйлар. Теге кош исә, авызын ачып, күккә карап тик ята.

Усалланган кошларны малай куып җибәрде. Һәм ни күзе белән күрсен, кыйналучы кош – кәккүк икән! Барысы да шунда аңлашылды. Кәккүк камыш чыпчыклары оясына йомырка салырга кергән дә аны бу кошлар куып чыгарганнар.

Малай кәккүкне дәү әнисе өенә алып кайтты. Озак та үтмәде, кәккүк ишек янындагы почмакка күкәй салды. Шуннан соң малай аңа оя ясады һәм кәккүкне шул ояга урнаштырды. Кәккүк, чыпчыклар кыйнагач, акылга утыргандыр, үз оясын саклар дип уйлады малай. Ләкин бик нык ялгышты! Кәккүк үзе салган йомырканы да, оясын да ташлап качты.

- Үзеңдә булмаса, кыйнап кына акылга утыртып булмый инде аны, - диде дәү әни. *(Әхсән Баяннан)*

**9** Малай нindидер тавышлар ишетә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Малай бик озак балык тотып утыра.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Камыш чыпчыклары кечкенә генә кошны кыйныйлар иде.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Кыйналган кош хәрәкәтсез ята.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Малай кошлар сугышын карап кына торды.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**14** Кәккүк яралы иде.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**15** Малай кошны әбиләренә алып кайта.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**16** Кәккүк оясын ташлап китә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**17**

Прочитайте тексты и установите соответствие между текстами **А – Е** и заголовками **1 - 8**. Запишите свои ответы в таблицу. Используйте каждую цифру **только один раз.** В задании есть **один лишний заголовок.**
Получившуюся последовательность цифр запишите в бланк ответов № 1 справа от номера соответствующего задания, начиная с первой клеточки. При переносе ответа на бланк следует указать только эту последовательность, **без запятых, пробелов и прочих символов.** Каждый символ пишите в отдельной клеточке в соответствии с приведёнными образцами.

1. **Көтүченең уйлануы**
2. **Күршеләрнең эте**
3. **Этнең тиеннәрне ялап куюы**
4. **Тиеннәр эт балалары белән**
5. **Урманга бару**
6. **Тиеннәрне эт оясына кую**
7. **Тиен балаларын алып кайту**
8. **Ят кош балаларын чыгару**

**А.** Кошларның ят кош йомыркасыннан бала чыгаруы беркемне дә гаҗәпләндерми. Ә хайван һәм җәнлекләр белән андый хәлнең булганын ишеткәнем юк иде. Сирәк булса да була икән.

**Ә.** Көтүче абый урманнан бик кечкенә тиен балаларын алып кайта. Алар бик хәлсез булалар. Безнең урманнарда тиеннәр бик аз. Беткән дәрәҗәдә диярлек. Бу ике тиен баласы үлсә, алар тагын да кимерләр.

**Б.** Шуны уйлап, абый аларны терелтергә тырыша. Аларга сөт эчертәсе килә. Ләкин алар эчә белмиләр. Белмиләр һәм теләмиләр дә. Инде нишләргә? Көтүче абый уйлана башлый.

**В.** Күршеләренең этләре яңа гына балалаган иде. Абый шуны исенә төшерә. Актүшнең өч көчеге барлыгын ул белә. Этнең балаларын имезгәнен дә күргәне бар. Әниләре төсле аклы-каралы көчекләр – бик шаяннар. Гел уйнарга гына торалар.

**Г.** Көтүче абый тиен балаларын күршеләрнең эт оясына кертеп куя. Үзе күзәтеп тора. Эт тиен балаларына тимиме? Аларны кабып йота күрмәсен! ...

**Д.** Бераз карап торгач, ана эт тиеннәр янына килә. Аларны төрле яклап карап чыга. Аннары ялап куя. Димәк, Актүш аларны кабул итә. Шулчак көтүче абый да, тынычланып, эшенә китә.

**Е.** Хәзер авыл урамында, ана эткә ияреп, көчекләр генә түгел, ә тиен балалары да сикергәли. Башта бу күренешкә гаҗәпләнсәләр дә, авыл кешеләре дә күнектеләр. Алар бу гаилә дуслыгына сокланып елмаялар гына.

| **Текстлар** | **А** | **Ә** | **Б** | **В** | **Г** | **Д** | **Е** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Исемнәр** | | | | | | | |

**По окончании выполнения заданий 9 - 17 не забудьте перенести свои ответы в бланк ответов № 1. Обратите внимание на то, что ответы на задания А7-А14, В3 располагаются в разных частях бланка.**

### 3 нче бүлек

Ответы на задания **18 - 32** запишите в бланке ответов № 1 справа от номера соответствующего задания, начиная с первой клеточки. Каждый символ пишите в отдельной клеточке в соответствии с приведёнными образцами.

Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами 18 – 25 так, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию 18- 25.

| | | |
|---|---|---|
| **18** | Бүген шимбә, иртәгә ...................... барырга кирәк түгел. | МӘКТӘП |
| **19** | Дәресләр беткәч, без ...................... барырга булдык. | КИНО |
| **20** | .... роботлар турында фильм күрсәтәләр. | КИНОТЕАТР |
| **21** | Мин үземә һәм .... ике билет сатып алдым. | ДУС |
| **22** | Без ... рәттә алтынчы һәм җиденче урыннарда утырдык. | ӨЧ |

| | | |
|---|---|---|
| 23 | Чыннан да, бу фильм мавыктыргыч иде һәм .......... бик ошады. | БЕЗ |

| | | |
|---|---|---|
| 24 | Фильм ... тә, без роботлар турында озак сөйләштек. | БЕТӘРГӘ |

| | | |
|---|---|---|
| 25 | Мәктәпкә баргач, сыйныфташларыбызга да бу .... карарга киңәш итәчәкбез. | ФИЛЬМ |

Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами 26 – 32 так, чтобы они грамматически и лексически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами. Каждый пропуск соответствует отдельному заданию 26-32.

| | | |
|---|---|---|
| 26 | Гыйлем Камай ........................ галим булган. | ТАЛАНТ |
| 27 | Ул яшьтән … калган һәм тугыз яшеннән эшли башлаган. | ӘТИ |
| 28 | Ләкин егетнең белем алу ................. зур булган, ул үзлегеннән укырга өйрәнгән. | ТЕЛӘ |
| 29 | Соңрак Гыйлем Камай укытучылар хәзерләү мәктәбен .... . | ТӘМАМ |
| 30 | Ул Томск университетының химия … дә укыган. | БҮЛ |
| 31 | Университетны … тәмамлагач, аны Казанга күчергәннәр. | УҢЫШ |
| 32 | Гыйлем Камай 1935 нче елдан органик химия кафедрасы белән җитәкчелек итә ......................, ә соңрак Казан университеты ректоры да булып эшләгән. | БАШ |

**По окончании выполнения заданий 18 – 32 не забудьте перенести свои ответы в бланк ответов № 1.**

## 4 нче бүлек

Для ответа на задания 33-38 используйте бланк ответов № 2.
При выполнении заданий 33 - 38 обратите внимание на то, что ваши ответы будут оцениваться только по записям, сделанным на бланке № 2. Записи в черновиках при проверке экспертом не учитываются.

В заданиях 33-37 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

33 1. Познакомьте родителей со своим (своей) новым другом (новой подругой).

34 2. Уточните у прохожего, где находится остановка автобуса.

35 3. Поинтересуйтесь у сестры, кем она хочет стать.

36 4. Спросите, у кого есть толковый словарь татарского языка.

37 5. Пожелайте одноклассникам успехов на экзаменах.

38 **Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Шушы сорауларга җавап биреп, аңа хат языгыз. Язма эшегез 80 сүздән торырга тиеш.**

*... Каникулда мин шәһәргә туганнарыбызга кунакка бардым. Мин бу шәһәр белән таныштым, төрле урыннарда булдым. Апам мине тәмле ризыклар белән сыйлады.*

*... Синең кайда кунакта булганың бар? Синең быел җәен кая кунакка барасың килә? Ни өчен?*

## Тексты для аудирования
## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

| |
|---|
| Сейчас Вы будете выполнять задания по аудированию. Каждый текст прозвучит 2 раза. После первого и второго прослушивания у Вас будет время для выполнения и проверки заданий. Все паузы включены в аудиозапись. Остановка и повторное воспроизведение аудиозаписи не предусмотрены. |

### Задание 1

| |
|---|
| Вы услышите четыре коротких диалога, обозначенных **А, Ә, Б и В.** Определите, где происходит каждый из этих диалогов. Используйте каждое место действия из списка **1-5 только один раз.** В задании есть **одно лишнее место действия.** Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу.<br>У Вас есть 20 секунд, чтобы ознакомиться с заданием. |

**Диалог А.**
А: Гафу итегез, спорт киемнәре бүлеге кайда?
Ә: Икенче катта.
А: Сез беләсезме, анда чаңгы ботинкалары саталармы?
Ә: Минемчә, булырга тиеш.
А: Рәхмәт Сезгә.
Ә: Исән-сау булыгыз.

**Диалог Ә.**
А: Сәлам!
Ә: Сәлам!
А: Поезд килгәнче, кафега кереп, чәй эчик.
Ә: Кафе еракмы соң?
А: Юк, ерак түгел.
Ә: Ярый. Әйдә, киттек.

**Диалог Б.**
А: Хәерле кич!
Ә: Исәнмесез!
А: Урыннарыгыз партердамы?
Ә: Әйе, уналтынчы рәттә.
А: Ә безнең урыннар унсигезенче рәттә.

**Диалог В.**
А: Ял көне кайда булдыгыз?
Ә: Бакчада.

А: Бакчагыз кайда урнашкан?
Ә: Идел буенда.
А: Анда нишләдегез?
Ә: Җиләк җыйдык, яшелчәләргә су сиптек.

**Задание 2**

Вы услышите пять высказываний. Установите соответствие между высказываниями каждого говорящего **А – Г** и утверждениями, данными в списке **1- 6**. Используйте каждое утверждение из списка 1-6 **только один раз.** В задании есть **одно лишнее утверждение.**
Вы услышите запись дважды. Занесите свои ответы в таблицу. У Вас есть 30 секунд, чтобы ознакомиться с заданиями.

**Сөйләүче А**

Дәрестә без Татарстан турында сөйләштек. Татарстан – сәнәгать үзәге. Биредә самолётлар һәм вертолётлар, "КамАЗ" машиналары һәм автомобиль шиннары, суыткычлар һәм медицина җиһазлары эшләнә. Татарстанда эшләнгән әйберләр төрле илләргә чыгарыла. Республикабызга да әлеге илләрдән төрле товарлар кертелә.

**Сөйләүче Ә**

"КамАЗ" заводы 1969 нчы елда төзелә башлый. 1976 нчы елның 16 нчы февралендә беренче машина конвейердан төшә. "КамАЗ" машиналары Россиядә чыга торган автомобильләрнең 60 % ын тәшкил итә. Йөк машиналарын төрле илләр сатып ала.

**Сөйләүче Б**

Татарстан – танылган мәдәни үзәк. Биредә атаклы театрлар, музейлар, югары уку йортлары, концерт заллары, китапханәләр эшли. Республикабызда ел саен халыкара классик балет фестивале, халыкара опера фестивале, мөселман фильмнары фестивале үткәрелә.

**Сөйләүче В**

Казан – борынгы шәһәр. Ул Казансу елгасы буенда урнашкан. Анда тарихи урыннар, мәйданнар, һәйкәлләр бик күп. Башкалабызның үзәгендә Кремль балкып тора. Казанга рәхим итегез!

**Сөйләүче Г**

Казан – спорт үзәге. 2013 нче елда Казанда Бөтендөнья Универсиада узды, төрле илләрдән бик күп спортчылар килде. Шәһәрдә бик күп яңа спорт корылмалары төзелде. Аларда төрле ярышлар үткәрелде. Шәһәр халкы барлык уеннарга да яратып йөрде.

## Задания 3 – 8

Вы услышите разговор двух друзей. В заданиях **3 – 8** обведите цифру **1, 2 или 3,** соответствующую выбранному Вами варианту ответа. Вы услышите запись дважды. У Вас есть 60 секунд, чтобы ознакомиться с заданиями.

Самат: Сәлам, Мөнирә!
Мөнирә: Исәнме, Самат!
Самат: Син кая барасың?
Мөнирә: Спорт мәктәбенә.
Самат: Син спорт белән шөгыльләнәсеңмени?
Мөнирә: Әйе, фигуралы шуу белән шөгыльләнәм.
Самат: Ничә ел инде?
Мөнирә: 5 яшьтә шөгыльләнә башладым.
Самат: Атнага ничә тапкыр тренировкалар була?
Мөнирә: Өч тапкыр.
Самат: Ярышларда да катнашасыңмы?
Мөнирә: Әйе. Ел саен катнашам.
Самат: Уңышларың бармы соң?
Мөнирә: Әлбәттә. Быел республика беренчелегендә беренче урын алдым.
Самат: Котлыйм.
Мөнирә: Ә син нәрсә белән кызыксынасың, Самат?
Самат: Миңа информатика дәресләре бик ошый.
Мөнирә: Компьютер уеннарын яратасыңмы?
Самат: Юк, уйнарга яратмыйм, программалар төзергә яратам.
Мөнирә: Кызык.
Самат: Мин информатика түгәрәгенә дә йөрим. Анда безне күп нәрсәгә өйрәтәләр. Без олимпиадаларда да катнашабыз.
Мөнирә: Призлы урыннар алдыгызмы соң?
Самат: Әйе, былтыр республикада җиңдек. Аннары Мәскәүгә дә бардык.
Мөнирә: Сине уңышларын белән котлыйм.
Самат: Рәхмәт, Мөнирә. Сиңа да уңышлар телим.
Мөнирә: Яхшы. Сау бул!
Самат: Сау бул!

# ОТВЕТЫ

## Җаваплар

### Задание 1

| Диалог | А | Ә | Б | В |
|---|---|---|---|---|
| Место действия | 5 | 4 | 3 | 2 |

### Задание 2

| Говорящий | А | Ә | Б | В | Г |
|---|---|---|---|---|---|
| Утверждение | 4 | 2 | 3 | 1 | 5 |

### Задания 3-32

| Номер задания | Правильный ответ | Номер задания | Правильный ответ |
|---|---|---|---|
| *3* | 3 | *18* | МӘКТӘПКӘ |
| *4* | 2 | *19* | КИНОГА |
| *5* | 1 | *20* | КИНОТЕАТРДА |
| *6* | 3 | *21* | ДУСТЫМА |
| *7* | 2 | *22* | ӨЧЕНЧЕ |
| *8* | 1 | *23* | БЕЗГӘ |
| *9* | 1 | *24* | БЕТКӘЧ |
| *10* | 2 | *25* | ФИЛЬМНЫ |
| *11* | 2 | *26* | ТАЛАНТЛЫ |
| *12* | 1 | *27* | ӘТИСЕЗ |
| *13* | 2 | *28* | ТЕЛӘГЕ |
| *14* | 2 | *29* | ТӘМАМЛАГАН |
| *15* | 1 | *30* | БҮЛЕГЕНДӘ |
| *16* | 1 | *31* | УҢЫШЛЫ |
| *17* | 8712634 | *32* | БАШЛАГАН |

## Критерии оценивания выполнения задания 38 “Личное письмо”

## Шәхси хат язу биремен бәяләү критерийлары

| К | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К1 | Коммуникатив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган:*** 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән | ***Эш өлешчә башкарыл-ган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган | ***Эш башкарылмаган:***:2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме тулмый |
| К2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләрдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килми. |
| К3 | Текстның лексик-грамматик төзелеше | Коммуникатив бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 төгәлсезлек рөхсәт ителә) | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик һәм грамматик чаралар кулланылган | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә торган 1-2 грамматик хата бар | Текстны аңлауга зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк |
| К4 | Орфография һәм пунктуация | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | пунктуацион хата бар | |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса) бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме **40** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**